**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2022 елның «28» апреленнән № 137

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Кызыл Октябрь авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын эшләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Кызыл Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү, килештерү, халыкка җиткерү һәм кабул итү процедурасына керешергә. Гамәлдәге законнарда һәм муниципаль-хокукый актларда каралган тәртиптә башкарырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Кызыл Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү срогын билгеләргә - җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү буенча техник бирем нигезендә 95 көн.

4. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасының «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми порталына //pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтына http://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р. Фасахов